**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы**
**Олы Чакмак авыл җирлегенә керүче Олы Чакмак авылы**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **06.12.2019 ел**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль
районының Олы Чакмак авыл җирлеге составына керүче
Олы Чакмак торак пунктына 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Олы Чакмак авыл җирлеге Олы Чакмак торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ**:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Олы Чакмак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә. Көндезге формада укучы студентларга, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, тыл ветераннарына 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Олы Чакмак авылы янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүгә, янгын сүндерү машинасын карау;
- Олы Чакмак авылы мәдәният оешмалары хезмәтләре белән ял вакытын оештыру һәм халыкны тәэмин итү өчен шартлар тудыруга;
- Набережная урамындагы 800 метр юлны карау;
-Җәй һәм кыш көне авылдагы юлларны чистарту, карау;
- Авылдагы урам утларын карау;
- Авыл территориясен төзекләндерү;
- Мәктәп территориясен төзекләндерү;
- “Сабантуй” паркын төзекләндерү;
- Авыл клубы территориясен төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Олы Чакмак авылы, Центральная урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Чакмак авыл җирлеге башлыгы Габидуллин И.М.